**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы №119 «15» октябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2023 елның 02 ноябрь 93 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (20.03.2024 № 105 карар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Сарлы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2023 елның 02 ноябрь 93 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (20.03.2024 № 105 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 8 өлешендә:

а) 6 пунктчада «бирелә» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләгән көннән дә соңга калмыйча,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 8 пунктчаны өстәргә:

«8) бюджетка түләүләр буенча дебитор бурычларын, пенялар һәм штрафлар буенча Россия Федерациясе Финанс Министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгели;»;

в) 8 пунктчаны 9 пунктча дип санарга;

1.2. 14 статьяның 1 өлешендәге икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль контрактлар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр закупкаларының план-графигы нигезендә (Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый план-графикка кертелергә тиешле сатып алу очракларыннан тыш) төзелә һәм, Россия Федерациясе БК статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түләнә.»;

1.3. 46 статьяның 2 өлешендә «паспортлар тапшырыла» сүзләрен «паспортлар (паспорт проектлары) тапшырыла» сүзләренә алмаштырырга, «күрсәтелгән паспортларга үзгәрешләр проектлары» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай районы Сарлы җирлеге Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.М.Камалетдинов